КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 сентябрь г.Казань № 1022

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 26 апрель, 345 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2019 ел, 26 апрель, 345 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 23 октябрь, 952 нче; 2021 ел, 30 декабрь, 1332 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «40 170» саннарын «41 777» саннарына алмаштырырга;

7 пунктның беренче абзацында «11 498» саннарын «11 958» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карар 2022 елның 1 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин